**Министерство образования и науки Республики Татарстан**
**Муниципальное бюджетное учреждение дополнительного образования**
**«Дворец творчества детей и молодежи имени. И.Х. Садыкова»**
**Нижнекамского муниципального района**
**Республики Татарстан**

ПРИНЯТА
на заседании педагогического совета
МБУ ДО «ДТДиМ
им. И.Х. Садыкова» НМР РТ
Протокол № 1
от «31» августа 2022 г.

УТВЕРЖДАЮ
Директор МБУ ДО «ДТДиМ
им. И.Х. Садыкова» НМР РТ
_____________Р.Н. Салихзянов
Приказ № 211
от «31» августа 2022 г.

# ДОПОЛНИТЕЛЬНАЯ ОБЩЕОБРАЗОВАТЕЛЬНАЯ ОБЩЕРАЗВИВАЮЩАЯ ПРОГРАММА «ТУГАН ЯК ТАБИГАТЕН ӨЙРӘНҮ»

***Направленность:*** туристско-краеведческая
***Возраст учащихся:*** 7-12 лет
***Срок реализации:*** 3 года (576 часов)

***Автор-составитель:***
Галимова Золфира Котдусовна,
педагог дополнительного образования

Нижнекамск, 2022 год

## Укыту программасының информацион картасы

| | | |
|---|---|---|
| 1 | Белем бирү оешмасы | Өстәмә белем бирү муниципаль бюджет учреждениесенең “И.Х. Садыйков исемендәге Балалар һәм яшьләр иҗаты сарае” |
| 2 | Программаның тулы исеме | “Туган як табигатен өйрәнү” |
| 3 | Программаның юнәлеше | Төбәк-туристлык |
| 4 | Программаны төзүчеләр турында мәгълүмат | |
| 4.1 | Ф.И.О. | Галимова З.К., югары категорияле өстәмә белем бирү педагогы |
| **5** | Программа турында мәгълүмат: | |
| 5.1 | гамәлгә ашыру вакыты | 3 ел |
| 5.2 | укучыларның яше | 7-12 яшькә кадәр |
| 5.3 | программага характеристика:<br>- программаның тибы<br>- программаның төре<br>- программаны проектлау принциплары<br>- укыту процессын оештыру эчтәлеге формасы | Үстерелешле өстәмә гомуми белем бирү программасы<br>авторлык<br><br>дәрес |
| 5.4 | программаның максаты | Туган ягыбызда үскән үсемлекләрне өйрәнү, табигатькә мәхәббәт һәм сакчыл караш тәрбияләү |
| 6. | Белем бирү программасының формалары һәм алымнары | Балалар берләшмәсе.<br>Проблемалы-эзләү ысуллары, мөстәкыйль һәм гамәли эшләр, төрле дәрәҗәдәге бәйгеләр, күргәзмәләр |
| 7. | Нәтиҗәлелекне мониторинглау формалары | Тестлар, биремнәр, кичәләр, төрле дәрәҗәдәге бәйгеләр, күргәзмәләр, проект эшләре, викториналар |
| 8. | Программаның нәтиҗәлелеген тормышка ашыру | |
| 9. | Программаны раслау һәм соңгы үзгәртү датасы | 31.08.2022 |
| 10. | Рецензентлар | Манихова Файруза Яхиновна, кандидат педагогических наук |

# Эчтәлек

1. Аңлатма язуы ........................................................................ …… 4-10
2. Укыту планы
    1 нче укыту елы ………………………………………………….…. 11
    2 нче укыту елы …………………………………………………..… 13-14
    3 нче укыту елы …………………………………………………..… 16-17
3. Укыту планы эчтәлеге
    1 нче укыту елы …………………………………………………...... 12
    2 нче укыту елы …………………………………………………….. 15
    3 нче укыту елы …………………………………………………….. 18
4. Программаның педагогик – оештыру шартларын тормышка ашыру ……..…………………………..….. 19-34
5. Әдәбият исемлеге ………………………………………………………… 35
6. Кушымталар……………………………………………………………… 36
    Кушымта 1. Методик материаллар ……………………………………… 36-40
    Кушымта 2. Календарь укыту график 1 нче укыту елы ………………….. 41-45
    2 нче укыту елы ………………….. 46-51
    3 нче укыту елы ………............. 52-57
    Кушымта 3. ТР Түбән Кама муниципаль районының “И.Х.Садыков исемендәге балалар һәм яшьләр иҗаты сарае” өстәмә белем бирү муниципаль бюджет учреждениесенең тәрбия программасын тормышка ашыру кысаларында тәрбия эше планы ......................................................................................... 58-61

## АҢЛАТМА ЯЗУЫ

“Туган як табигатен өйрәнү” программасы төбәк-туристлык юнәлешендәге программа.

Программа төп *норматив документлар* нигезендә төзелде:

- Бала хокуклары турында БМО конвенциясе;
- Программа “Россия Федерациясендә мәгариф турында” 29.12.2012 ел, № 273-ФЗ;
- Балаларга өстәмә белем бирүне үстерү концепциясе, 31.03.2022 ел, № 678-р;
- “Мәгариф” милли проекты кысаларында “Һәр баланың уңышы” федераль проекты, Россия Федерациясе Президенты каршындагы стратегик үсеш һәм милли проектлар советы президиумының 2018 елның 3 сентябрендәге 10 номерлы утырышы беркетмәсе белән расланган “Мәгариф” милли проекты;
- Россия Мәгариф министырлыгының “Балаларга өстәмә белем бирүнең төбәк системаларын үстерүнең максатчан моделен раслау турында” 2009 елның 3 сентябрендәге 467 номерлы боерыгы;
- Россия Федерациясе Мәгариф министрлыгының “өстәмә гомуми белем бирү программалары буенча белем бирү эшчәнлеген оештыру һәм гамәлгә ашыру тәртибен раслау турында” 2018 елның 9 ноябрендәге 196 номерлы боерыгы;
- РФ Мәгариф һәм фән министрлыгының 23.08.2017 ел, № 816 боерыгы белем бирү эшчәнлеген, электрон белем бирүне, дистанцион белем бирү технологияләрен гамәлгә ашырганда куллану тәртибен раслау турында;
- СП 2.4. 3648-20 “санитар – эпидемиологик таләпләр” РФ Баш дәүләт санитар табибының 28.09.2020 ел, № 28 карары белән расланган “балаларны һәм яшьләрне тәрбияләү, укыту, ял итү һәм сәламәтләндерү оешмаларына” дигән темага ТР Министырлар кабинеты карары;
- Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы “И.Х. Садыйков исемендәге Балалар һәм яшьләр иҗаты сарае” уставы;
- Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы “И.Х. Садыйков исемендәге Балалар һәм яшьләр иҗаты сарае” балаларга өстәмә белем бирү программасын эшләү һәм раслау турында нигезләмә.

*Программаның актуальлеге.* Дәрестән тыш эшчәнлекнең эстетик – сәнгать юнәлеше укучының танып белү һәм иҗади активлыгын арттыра, шәхси сыйфатларын яхшыртырга мөмкинлек бирә. Төрле төрдәге чаралар, кичәләр баланың физик, акыл үсешенә һәм психикасына уңай йогынты ясый.

Татар халкының борын-борыннан формалашып килгән рухи культурасы, бай хәзинәсе бар. Шуңа күрә дә укучыларны татар халкының гореф-гадәтләре, ел фасыллары, табигать күренешләре, үсемлек һәм җәнлекләр дөньясы белән таныштыру бик файдалы эш. Чөнки кече яшьтәге мәктәп балаларына табигатьтәге һәр күренеш серле һәм кызыклы булып тоела.

Туган ягыбыз табигать байлыкларына – урман, суларга бай як. Шуңа да әби-бабайларыбыз табигатьнең бөтен мөмкинлекләрен сәламәтлекне ныгыту максатында бик борынгы заманнардан ук куллана башлаганнар. Дару үләннәре элек-электән кешеләр өчен яшәү, азык һәм сәламәтлек чыганагы булып торганнар. Аларны куллану турындагы мәгълүматлар буыннан буынга бирелеп килгән. Бу турыда борынгы риваятьләрдә һәм экиятләрдә дә күп тапкырлар искә алына. Бүгенге көндә

дә, фән һәм техника чәчәк аткан заманда, дару үсемлекләре үзләренең әһәмиятләрен югалтмадылар. Әле һаманда бик күп авыруларны, шул исәптән, киң таралган йөрәккан тамырлары авыруларын күп очракта үсемлек чималы ярдәмендә генә дәвалап була. Шуңа күрә, медицина практикасы дару үләннәрен, һәртөрле үсемлекләрне киң куллануны хуплый.

Хәзерге вакытта дару үсемлекләрен җыю, киптерү, саклау, аларны куллану турында мәгълүматлар язылган китаплар күп бастырылып чыгарыла.

Яшь буын үзләре яшәгән төбәктә нинди дару үсемлекләре үсүен һәм аларны куллану ысулларын белергә тиешләр.

*Педагогик максатчанлык*

“Туган як табигатен өйрәнү” берләшмәсендә иң төп юнәлешләрнең берсе булып тәрбия эше тора. Ә тәрбия эшенең төп бурычы – шәхескә тормышта үз юлын табарга өйрәтү, аның сәләтен үстерү, өлкәннәргә карата миһербанлы-шәфкатьлелек, кечеләргә карата ихтирамлылык,табигатькә карата сакчыл караш тәрбияләү тора. Туган ягыбызның батыр, легендар шәхесләре белән горурлана белү кебек сыйфатларга да түгәрәккә йөреп ия була бала. Программа укучыларның дәрестән тыш вакытларын файдалы үткәрү, күмәк эшчәнлек, кызыксыну, иҗади сәләтләрне үстерү максатыннан чыгып төзелде.

Табигать – безнең иң зур байлыгыбыз. Тирә – юньне пычрату кешеләр тарафыннан уйламыйча эшләнә торган зур ялгышлык. Хәзерге вакытта табигатьне саклау иң әһәмиятле мәсьәләләрнең берсе булып тора.

*Программаның башка программалардан үзгәлеге*

Башка “Туган як табигатен өйрәнү” программаларыннан үзгә буларак түбәндәге программада башлангыч сыйныф укучылары белән фәнни-гамәли эшләрнең беренче адымнарны ясау кертелгән. Күзәтергә, эзләнергә, фикерләргә, шул фикерне ачык итеп әйтә белергә, проект эшендә куллана белергә өйрәтә. Укучылар өчен үсемлекләр, яшелчә, җиләк-җимешләрнең төрле сортларын яңа алымнар белән үстерү кызыклы булганга программага шушы юнәлешкә дә өстенлек бирелгән.

*Укучыларга дистанцион ярдәм күрсәтү формалары*

Программаны тормышка ашырганда, мәгълүмати һәм компьютер технологияләре, шулай ук дистанцион укыту формалары актив кулланыла. Алынган белемнәрне ныгыту, гамәли күнекмәләрне камилләштерү өчен сайтлар белән дистанцион хезмәттәшлек алып барыла:

https://tatarica.org/ru/razdely/nauka/nauchnye-obshestva/obshestvo-izucheniya-tatarstana
https://infourok.ru
https://multiurok.ru
http://www.protown.ru (Федеральный краеведческий портал)
http://ru.wikipedia.org (Википедия. Свободная энциклопедия).
http://www.virtan.ru (Природа России).
http://www.mycicerone.ru(сайт по краеведению России).
http://journal-shkolniku.ru/virtual-ekskursii.html (сайт виртуальных экскурсий)
http://culttourism.ru/ (Справочник культурно-исторических достопримечательностей России: музеи, архитектура, усадьбы, памятники).
http://www.ru-regions.ru/(Информационный портал «Знакомство с Россией»).
http://russia-karta.ru (Электронная карта России).

http://azbukivedi-istoria.ru/
http://www.biografija.ru (Биографическая энциклопедия)
http://school-collection.edu.ru/catalog/res/f6c85ff7-9567-4b28-b441-b270d163899c/?sort=order&interface=tla&rubric_id[]=89593&rubric_id[]=89623 ЦОР «Живая родословная»
http://naar.ru/articles/kak-sostavit-rodoslovnuyuposhagovaya-instruktsiya/Как составить родословную
http://geno.ru/news/7771/ Программа «Российские династии»
http://www.excurs.ru/pravila.htm Основные правила геральдики
http://redirina.ucoz.ru/ Сайт-проект «Фамильный герб»

**ПРОГРАММАНЫҢ МАКСАТЫ:** укучыларны туган ягыбыз табигате, аның табигый байлыклары белән тирәнтен таныштыру, туган ягыбыз табигатен өйрәнүгә нигезләнеп укучыларда туган ягыбызга мәхәббәт һәм сакчыл караш тәрбияләү.

**БУРЫЧЛАР:**

*белем бирү*:

укучыларда шәхси иҗади сыйфатлар һәм милли үзан булдыру, Татарстан Республикасы территориясендә яшәүче халыкларның тарихи һәм рухи традицияләрен, мәдәниятләрен, тормыш-көнкүрешләрен, хайваннар һәм үсемлекләр дөньясы белән якыннан танышу, сәламәтлекне ныгыту максатында халык медицинасы белән кызыксынуны үстерү, аларны тормышта куллана белергә өйрәтү;

*үстерү*:

балаларда рухи хәзинәбезгә ихтирам уяту, шәфкатьлелек, инсафлылык элементлары тәрбияләү, тирә-як мөхитне саклау, аны яшелләндерү, баету өстендә эшләү, экологик белем бирү һәм балаларны чын табигать хуҗалары итеп тәрбияләү, танып-белү, күзәтүчәнлек кебек сыйфатларны үстерү;

*тәрбия бирү*:

балаларда мөстәкыйльлек, хезмәт культурасына, табигатькә һәм туган якка мәхәббәт тәрбияләү, дуслык, ярдәмчеллек сыйфатлары тәрбияләү.

*Программаны тормышка ашыруда катнашучы балаларның яше:*

“Туган як табигатен өйрәнү” программасы башлангыч сыйныфта укучы балалар (7-12 яшькә кадәр) өчен аларның яшь үзенчәлекләрен һәм материал-техник базаны истә тотып язылган. Берләшмәгә укучылар үз теләкләре белән, педагог һәр бала белән индивидуаль әңгәмә уздырганнан соң кабул ителә. Программа буенча төркемнәрдә 1нче ел укытуда 15 бала, 2нче ел укытуда 10 бала, 3нче ел укытуда 10 бала шөгылләнә.

*Программаның күләме:*

Беренче ел берләшмәгә йөрүче балалар уку елы барышында 144 сәгать, икенче ел 216 сәгать, ә өченче ел шөгыльләнүче балалар 216 сәгать шөгыльләнәләр. Программаның гомуми күләме - 576 сәгать.

*Белем бирү процессын оештыру формалары:*

Программа өч ел укытылуга язылган. Программа өстәмә белем бирү педагогыннан фәнни-педагогик әзерлеккә ия булуны таләп итә. Укытучының филология, тарих, технология, рәсем сәнгате, табигать белеме дәресләре буенча билгеле бер күләмдә белеме, сәләте, күнекмәләре булырга тиеш. Һәрдаим эзләнгәндә, бай материал туплап,

белгечләр белән киңәшләшеп, укучыларны эшчәнлеккә җәлеп иткәндә, яхшы нәтиҗәләргә ирешергә мөмкин.

Белем бирү программасы шактый катлаулы, шуңа күрә берләшмәгә йөрүче балаларның дәресләргә системалы йөрүе кирәк.

Эш тәҗрибәсе шуны күрсәтә: теоретик материал һәр дәрестә гамәли эш белән ныгытылырга тиеш. Шуны истә тотып программада гамәли дәресләр өстенлек итә:

– төрле очраклар өчен куркынычсызлык инструктажлары уздыру һәм журналларда теркәү;

– елның төрле вакытларында саф һавада уйнау өчен хәрәкәтле уеннар оештырып уздыру;

– муниципаль район, республика күләмендә үткәрелгән чараларда катнашу;

– төрле күләмдәге бәйгеләрдә катнашу;

– ата-аналар белән берлектә төрле чаралар уздыру;

– юлларда балалар травматизмын кисәтү буенча чаралар үткәрү;

– сәнгать эшлеклеләре белән очрашулар оештыру.

Берләшмә шөгыльләренең нигезенә теоретик һәм гамәли эшләр салынган. Төп игътибар туган якта үсүче, дәвалау үзлегенә ия булган үсемлекләрне өйрәнүгә, аларны төрле авыруларга каршы куллана белүне өйрәтүгә юнәлдерелгән. Үсемлек дөньясы кешеләргә дару үләннәре байлыгын бүләк иткән. Аларны тан үзләштерү һәр укучы өчен төп шарт булып тора.

Программага түбәндәгеләрне өйрәнү кертелгән:

– дару үсемлекләрен рациональ файдалану, аларның запасы кимемәсен өчен бакчаларда үрчетү;

– бакчада, дымлы урыннарда һәм сазлыкларда үсүче үсемлекләрне танып белү, үзенчәлекләрен үләннәрнең, яшелчә, җиләк-җимешләрнең файдалары, аларны куллану;

– урман, болын, кыр, чүп үләннәрен, агулы үсемлекләрне өйрәнү, алардан файдалана белү;

– аларны җыю, киптерү һәм саклау үзенчәлекләрен үзләштерү;

– ТР һәм РФ нең Кызыл китапларына кертелгән, кимеп һәм юкка чыгып баручы үсемлекләрне өйрәнү, аларны саклау;

– куркынычсызлык, санитария һәм гигиена таләпләрен төгәл үтәү кагыйдәләре;

– халкыбызның уеннарын, җырларын өйрәнү, бәйрәмнәр үткәрү.

Теоретик шөгыльләр белән беррәттән дару үләннәрен һәм табигый материалларын җыю, дару үләннәре белән чәй эчү, аларның рәсемнәрен ясау, дару үсемлекләре турында табышмаклар, шигырьләр уку, җырлар өйрәнү, дару үләннәрен куллану буенча рецептлар төзү кебек гамәли эшләр; урманга, бакчага, кырга, болынга, экологик сукмакка, даруханәгә, музейларга экскурсияләр үткәрү күздә тотыла.

Өч уку елы барышында да сәламәт яшәү рәвешен пропагандалау өчен алкоголь һәм наркотиклар кулланунын, тәмәке тартуның сәламәтлеккә зарары турында әңгәмәләр; сәламәтлекне саклау һәм ныгыту өчен дөрес туклану, саф һавада күбрәк йөрү, иртән гимнастика ясауның әһәмияте турында аңлатулар һәм хәрәкәтчән уеннар алып барыла. Шөгыль барышында балаларда аруны булдырмас өчен физкультминутлар үткәрелә.

Программада укыту формасы буенча эш фронталь, индивидуаль, парлап, звенолап һәм группалап оештырылырга мөмкин, ләкин ул ничек оештырылса да, коллектив эчендә шәхесара мөнәсәбәтләр тәрбияләүгә ярдәм итәрлек булырга тиеш.

Фронталь формада укыту материалны бөтен коллективка бирү юлы булса, звенолап һәм төркем белән эшләү юлында укучыларга сәләтләрен ачарга, бер-берсенең ярдәмен тоярга һәр конкрет этапта мөмкинлекләр туа.

Укучыларның укыту һәм тәрбия ихтыяҗларын үзенчәлекле итү өчен төркемнәр һәм төркемчекләр белән эшләү тәкъдим ителә (баланың яше һәм берләшмәдә эшләү тәҗрибәсе күздә тотыла). Индивидуаль форма укучының мөстәкыйль рәвештә шөгыльләнүен искәртә. Монда педагог ярдәме белән баланың эшчәнлеге арта, ул мөстәкыль эшләргә өйрәнә.

Укыту процессы вакытында түбәндәге дәрес формалары исәпкә алына:

– типовой дәресләр (үз эченә теоретик нигез белән танышу һәм теоретик нигезне ныгыту өчен кирәк булган күнегү һәм уеннарны ала);

– иҗади дәресләр (дәрес темасы буенча кул эшләнмәләре ясау, фәнни-гамәли конференцияләрдә катнашу);

– практик дәресләр (Балалар иҗаты сарае янындагы бакчада, теплицада төрле тәҗрибәләр үткәрү);

– видеоматериаллар карау;

– сюжетлы-уенлы һәм бәйге программалары.

*Программаны үзләштерү вакыты.* Программа өч ел укытуга язылган. Планлаштырылган нәтиҗәләргә ирешү мөмкинлеген программа эчтәлеге һәм көтелгән нәтиҗәләр билгели.

*Дәрес режимы.* Дәреснең дәвамлылыгы СП 2.4. 3648-20 (п. 2.10.2, 2.10.3, 3.6.2) таләпләренә туры килә. Укучылар белән дәресләр үткәрелә: 1нче ел уку - атнага 2 тапкыр 2 академик сәгать белән, тәнәфес 10 минут; 2нче, 3нче ел уку - атнага 2 тапкыр 10 минут тәнәфес белән 3 академик сәгать.

## ***Программаны үзләштерүнең планлаштырылган нәтиҗәләре***

*Беренче ел укытуда көтелгән нәтиҗәләр*

<u>*Метапредмет күрсәткечләре:*</u>

- иҗади бурычны аңлау;
- өстәмә әдәбият, төрле мәгълүмат чыганаклары белән эшли белү;
- эзлеклелекне саклау;
- индивидуаль, төркемдә эшләү;
- эшчәнлек нәтиҗәләрен рәсмиләштерү;
- башкарылган эшне тәкъдим итә белү.

<u>*Шәхси күрсәткечләр:*</u>

- активлык, идеяләр һәм тәкъдимнәр тәкъдим итәргә әзер булу;
- ихтыяр көче, максатка ирешүдә ныклык күрсәтү;
- төркемдә эшләү күнекмәләренә ия булу;
- сәламәтлекнең кыйммәтен аңлау;
- җаваплылык, башкаручанлык, хезмәт сөючәнлек, иптәшләренә ихтирамлылык күрсәтү;

- гомуми иҗади эшкә җәлеп итү аша коллектив үзара бәйләнешкә ихтыяҗ һәм күнекмәләр күрсәтү.

*Предмет күрсәткечләре*:

*Беренче ел уку ахырына укучы беләчәк*:
- туган ягыбызда үсүче үсемлекләрне таный, аера белә;
- дару үсемлекләрен дөрес куллана белә;
- үсемлекләрне үрчетә, үстерү кагыйдәләрен белә;
- тирә-як мөхитне саклау һәм яшелләндерү кагыйдәләрен белә;
- шәһәребезнең бөек шәхесләрен белә;

*булдырачак*:
- эш урынын дөрес оештыра һәм эш вакытында тәртипне саклый;
- үз фикерләрен мөстәкыйль дәлилли;
- татар халкының мәдәниятен, тарихын, гореф – гадәтләре турында сөйли белә.

*Икенче ел укытуда көтелгән нәтиҗәләр*

*Метапредмет күрсәткечләре:*
- урман тормышы, болын, сулыклар турында алган белемнәрен тормышта куллана белү;
- үсемлекләрне тышкы кыяфәтенә карап аера, мисаллар китерә белү;
- әйләнә-тирә дөньяда үзеңне тоту кагыйдәләренең нигезен аңлап эш итү;
- эзләнү, күзәтү, җыйналган материаллардан чыгып, проект эше эшли белү;
- план буенча эш итү һәм үз эшчәнлегеңне планлаштыру;
- бәяләүләрне һәм билгеләрне дөрес кабул итү;
- башка укучыларның җавапларын гадел бәяләү;
- үз-үзеңне танып белү һәм дөньяны танып белү ысулы буларак иҗади эшчәнлек белән кызыксыну;
- өстәмә әдәбият, төрле мәгълүмат чыганаклары белән эшләү;
- эшчәнлек нәтиҗәләрен эстетик яктан рәсмиләштерү.

*Шәхси күрсәткечләр:*
- максатка ирешү, авырлыкларга бирешмәү, җиңәргә әзер булу, җаваплылык, тырышлык, хезмәт сөючәнлек, пөхтәлек күрсәтү ;
- төркемнәрдә бердәм иҗади эшкә җәлеп итү , коллектив аша үзара ихтыяҗын һәм күнекмәләрен күрсәтү;
- эшчәнлек барышында үзеңә дөрес бәяләү сәләте.

*Предмет күрсәткечләре:*

*Икенче ел уку ахырына укучы беләчәк*:
- алган белемнәрен тормышта куллана белә;
- алынган белем – мәгълүматларны камилләштерә, киңәйтә белә;
- эшенең дөреслеген контрольдә тоту;
- парда, коллективта эшли белә;

*булдырачак:*
- халкыбызның үткәне, бүгенгесе турында сөйли.
- үз фикерләрен мөстәкыйль дәлилли;
- үсемлекләр дөньясы турында кечкенә информация бирә белә.

*Өченче  ел укытуда көтелгән нәтиҗәләр*
*<u>Метапредмет күрсәткечләре:</u>*
- безнең планета  исемен, туган ил һәм аның башкаласын, үзе яшәгән регионын, туган шәһәренең тарихын, байлыкларын тезмә сөйләп бирә белү;
- әйләнә-тирә дөньябызда  үсүче үсемлекләрнең исемнәрен белү, дару үләннәрен тормышта куллана белү;
- төрле чараларда, бәйгеләрдә алган белемнәрен, күнекмәләрен  күрсәтә белү;
- “Уйланабыз, эзләнәбез, шәһәрем синең хакта” гамәли эзләнү проект эшендә актив катнашу;
- үз фикереңне исбатлый һәм яклый алырга күнектерү;
- мөстәкыйль  өстәмә әдәбият, төрле мәгълүмат чыганаклары белән эшләү;
- үз-үзеңне танып белү һәм дөньяны танып белү ысулы буларак иҗади эшчәнлек белән кызыксыну.

*<u>Шәхси күрсәткечләр:</u>*
- үзеннән тәкъдимнәр кертергә әзер булырга;
- максатларга ирешүдә үзеннән ихтыяр көче, үҗәтлек күрсәтергә;
- төркемдә эшли белергә;
- иптәшеңне тыңлый, ишетә белү, ишеткәнен үз фикере белән чагыштыру;
- үз фикереңне телдән һәм язма формада башкаларга җиткерә белү;
- эш барышында килеп чыккан проблемаларны уртага салып хәл итү;
- иптәшләренең фикерләре белән ризалашу.

*<u>Предмет күрсәткечләре:</u>*
*Өченче ел уку ахырына укучы беләчәк*:
- алган белемнәрне үзеннән тәкъдимнәр кертеп сөйли белә;
- максатларга ирешүдә үзеннән ихтыяр көче, үҗәтлек күрсәтә;
- төркемдә эшли белә;
- фактларны аңлата һәм исбатлый белә;
- сәламәтлекнең кыйммәте турында аңлап эш итә;
- җәяүлеләр өчен юл йөрү кагыйдәләрен белә;
- велосипедта хәрәкәтләнү таләпләрен белә;
- өстәмә әдәбият, төрле мәгълүмат чыганаклары белән эшли белә;
- иҗади бурычны аңлый;
- идеяләр, тәкъдимнәрне тәкъдим итәргә һәм күрсәтергә әзер;
- эшчәнлек нәтиҗәләрен рәсмиләштерә белә;

*булдырачак:*
- эшне тәртип буенча башкара;
- маршрут транспортларында, тукталышларда үз-үзеңне тоту кагыйдәләрен дөрес куллана;
- өйрәнелә торган материалны анализлый;
- коллективта үз-үзеңне дөрес тота.

***Программаны тормышка ашыруга йомгак ясау формалары***:

Укыту процессының нәтиҗәлелеген төрле  аттестация формалары күрсәтә:

Кереш контроль – диагностикасы группаларны җыйганда уку елы башында оештырыла. Максат – балаларның беренчел белем һәм күнекмәләренең ни дәрәҗәдә булуын ачыклау. Бәяләү формасы – сораштыру, анкеталар.

Агымдагы контроль – төп темаларны үзләштергәч уздырыла. Максат – темалар ни дәрәҗәдә үзләштерелгән һәм практик биремнәрдә куллана белү, белемнәрен ныгыту. Бәяләү формасы – тестлар, викториналар оештыру.

Арадаш контроль – беренче, икенче укыту елының азагында оештырыла. Максат – алган белемнәрен Балалар һәм яшьләр иҗаты сараенда уздырылучы кичәләрдә катнашу, шәһәркүләм, республика буенча оештырылган бәйгеләрдә актив катнашу.

Йомгаклау контроле – өч еллык укыту программасын үзләштергәннән соң йомгаклау күргәзмәсе формасында үткәрелә. Йомгаклау аттестациясен уңышлы үткән чыгарылыш укучыларына “Туган як табигатен өйрәнү” өстәмә гомуми белем бирү программасын үзләштерү турында таныклык бирелә.

## 1 ЕЛ УКЫТУГА УКУ ПЛАНЫ

| **№ п/п** | **Бүлек исеме, темалар** | **Сәгатьләр саны** | | | **Аттестация төрләре, тикшерү ысуллары** |
|---|---|---|---|---|---|
| | | Барлыгы | Теория | Практика | |
| 1. | **Кереш дәрес.** Куркынычсызлык кагыйдәләре. Кереш контроль “Мин табигать баласы” | 8 | 4 | 4 | Телдән сораштыру, күзәтү |
| 2. | **Туган як.** Табигый материаллар белән эшләү: кипкән яфраклар, чәчәклр, имән чыршы чикләвекләре һ.б. | 16 | 4 | 12 | Кечкенә-выставка, презентация эшләре |
| 3. | **Экологиянең мөһим нигезләре**. Экология турында төшенчә. Экология һәм сәламәтлек. Кеше экологиясе | 12 | 6 | 6 | Әңгәмә, аралашу, үзлектән эш, практик эш |
| 4. | **Бакча үсемлекләре.** Агачлар. Куаклар. Үләннәр. Яшелчәләр. Тәмләткечләр. Агымдагы контроль | 44 | 24 | 20 | Конкурс-викторина. Сораштыру. Практик эш |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| 5. | **Җылы якларда үсүче җиләк-җимешләр, яшелчәләр** | 18 | 2 | 16 | Кечкенә-выставка, сораштыру |
| 6. | **“Икенче тормыш”**. Табигать материалларыннан сувенирлар ясау | 30 | 4 | 26 | “Экология әлифбасы” проектын яклау |
| 7. | **Иҗади эшләр выставкасы** | 2 | - | 2 | Балалар эшләреннән выставка |
| 8. | **Экскурсияләр, бәйрәмнәр** | 8 | - | 8 | Эшлекле уен, аралашу, сораштыру |
| 9. | **Йомгаклау.** Укыту модуле “Юл куркынычсызлыгы”. Арадаш контроль | 6 | 2 | 4 | Телдән уен формасында сораштыру, ярыш. Тестлар ясау |
| | **Барлыгы:** | **144 с.** | **46 с.** | **98 с.** | |

## 1 ЕЛ УКЫТУГА ПРОГРАММА ЭЧТӘЛЕГЕ

**1 тема: Кереш дәрес.** Түгәрәкнең максаты, мәсьәләләре, үткәрү тәртибе. Куркынычсызлык һәм юл йөрү кагыйдәләре.

Халык медицинасы турында төшенчә. Борынгы кешеләрнең төрле үсемлекләрдән файдаланырга өйрәнүләре. Медицинага нигез салучы Гиппократ һәм башка борынгы табиблар белән таныштыру (Диоскорид, Авиценна һ.б.). Юл йөрү кагыйдәләре буенча әңгәмә. Кереш контроль № 1. Сораштыру.

*Күрсәтмә материал*: Обучение школьников правилам безопасного поведения на дороге (5-9 классы): Учебно-методическое пособие / Р.Ш. Ахмадиева, С.А. Бикчентаева, Д.Д. Забиров, Е.Е. Воронина и др./ Под общей ред. Р.Н. Минниханова, Д.М. Мустафина. – Казань: ГБУ «НЦ БЖД», 2020 г.

**2 тема: Туган як.** Туган ягым – Татарстан. Аның символикасы һәм атрибутикасы. Географик урыны, климатының үзенчәлекләре, үсемлек һәм хайваннар дөньясы белән таныштыру.

*Практика.* Татарстан республикасының флагын ясау. Бәйрәмнәр үткәрү. Көзге, кышкы, язгы табигатькә, музейларга экскурсияләр.

**3 тема: Экологиянең мөһим нигезләре.** Экология турында төшенчә. Экология һәм сәламәтлек. Кеше экологиясе. Тормыштагы экология.
*Практика.* РФ һәм ТР-ның Кызыл китаплары белән танышу. Экологик сукмак буйлап сәяхәт.
**4 тема: Бакча үсемлекләре.** Культуралаштырылган бакча агачлары, куаклары, дару үләннәре, яшелчәләр, тәмләткечләр. Аларның биологик үзенчәлекләре. Җимешләре, яфраклары, кайрылары дару өчен кулланыла торган агачлар, куаклар. Җиләк-җимешләр һәм яшелчәләрнең файдалары. Чәчәкләре, яфраклары, тамырлары дару өчен кулланыла торган үләннәр. Аларны җыю, киптерү, саклау. Дару чималын әзерләү һәм аны куллану кагыйдәләре.
*Практика.* Агачлар, үсемлекләр исеме белән аталган шигырьләр, табышмаклар белән танышу, җырлар өйрәнү. Рәсемнәр конкурсы үткәрү. Дару үләннәре белән чәй эчү. Яшелчәләрдән салатлар ясау. Юл йөрү кагыйдәләре буенча әңгәмә.
Агымдагы контроль. Тест № 2 “Туган ягым - Татарстан”.
**5 тема: Җылы якларда үсүче җиләк-җимешләр, яшелчәләр.** Җылы якларда үсүче җиләк-җимешләр, яшелчәләр: йөзем, өрек, әфлисун, лимон, грейпфрут, әстерхән чикләвеге, инҗир, карбыз, кавын, анар (гранат), авокадо, ананас, хөрмә, финик, киви. Аларның химик составы. Фәнни һәм халык медицинасында азык һәм дару чималы булып кулланылуы. Юл йөрү кагыйдәләре буенча әңгәмә.
*Практика.* Рәсемнәр конкурсы үткәрү. Белемнәрен тикшерү. Төрле җимешләр белән эчемлекләр әзерләү.
**6 тема: “Икенче тормыш”** Табигать материалларыннан сувенирлар ясау.
*Практика.* Бәйрәм формасында балаларның белемнәрен тикшерү. Арадаш контроль. Тестлар ясау. Иҗади эшләрдән выставка ясау.
**7 тема: Иҗади эшләр выставкасы**. Балалар ел буена эшләгән эшләреннән күргәзмә ясыйлар. Бер берсенең эшләренә бәя бирәләр.
**8 тема: Экскурсияләр. Бәйрәмнәр**. Туган шәһәребез паркыларына экскурсияләр оештыру. Табигать күренешләрен күзәтү.
**9 тема: Йомгаклау дәресе.** Түгәрәк эшчәнлегенең еллык эшенә нәтиҗә ясау. Фикерләр алышу. Алдагы елларга теләкләр. Юл йөрү кагыйдәләрен кабатлау.
Арадаш – контроль. Тест № 3 “Безнең як үсемлекләре”
*Практика.* Укыту модуле «Юл куркынычсызлыгы». Юл йөрү кагыйдәләрен уен формасында оештыру. Практик эшләр.

## 2 ЕЛ УКЫТУГА УКУ ПЛАНЫ

| № п/п | Бүлек исеме, темалар | Сәгатьләр саны | | | Аттестация төрләре, тикшерү ысуллары |
|---|---|---|---|---|---|
| | | Барлыгы | Теория | Практика | |
| 1. | **Кереш дәрес.** Куркынычсызлык кагыйдәләре. Кереш контроль. Тест | 6 | 3 | 3 | Кереш контроль. |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | № 4 | | | | Тест. Телдән сораштыру, күзәтү |
| 2. | **Туган ягым - Татарстан. Яшәгән җиребез.** Атрибутика һәм символика. Минем туган шәһәрем - Түбән Кама. Табигатькә экскурсия | 36 | 18 | 18 | Кечкенә-выставка, презентация эшләре |
| 3. | **Терек һәм терек булмаган табигать.** Безнең як табигатенең күренешләре. Һава торышы | 24 | 12 | 12 | Әңгәмә, аралашу, үзлектән эш, практик эш |
| 4. | **Экология һәм Мин.** Экологик сукмак буйлап сәяхәт. Кеше экологиясе. Тормыш экологиясе. Кызыл Китап. Агымдагы контроль. Тест № 5 “Табигатькә куркыныч яный!” | 48 | 30 | 18 | Конкурс-викторина. Сораштыру. Практик эш. Тестлар ясау |
| 5. | **Безнең урман байлыклары.** Дару үләннәре. Агулы үләннәр. Гөмбәләр. Аларны тормышта дөрес куллану | 36 | 18 | 18 | Кечкенә-выставка, сораштыру |
| 6. | **Татарстанда үсүче агулы үсемлекләр. Болын үсемлекләре**. Үләннәр. Аларның файдасы. Тормышта куллану. Гербарий ясау. Табигать материалларыннан сувенирлар ясау | 30 | 18 | 12 | «Экология әлифбасы» проектын яклау |
| 7. | **Иҗади эшләр күргәзмәсе** | 24 | - | 24 | Балалар эшләреннән выставка |
| 8. | **Йомгаклау**. Уку елына йомгак ясау. Балаларны тәбрикләү. Арадаш контроль. Викторина № 6 “Гөмбәләр дөньясында” | 6 | 3 | 3 | Эшлекле уен, аралашу, сораштыру |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| 9. | **Укыту модуле “Юл куркынычсызлыгы”.** Саф һавада хәрәкәтле уеннар | 6 | 3 | 3 | Телдән уен формасында сораштыру, ярыш |
| | **Барлыгы:** | **216 с.** | **105 с.** | **111 с.** | |

## 2 ЕЛ УКЫТУГА ПРОГРАММА ЭЧТӘЛЕГЕ

**1 тема: Кереш дәрес.** Түгәрәкнең максаты, бурычлары. Куркынычсызлык һәм юл йөрү кагыйдәләрен искә төшерү. Кереш контроль Тест № 4

*Күрсәтмә материал*: Обучение школьников правилам безопасного поведения на дороге (5-9 классы): Учебно-методическое пособие / Р.Ш. Ахмадиева, С.А. Бикчентаева, Д.Д. Забиров, Е.Е. Воронина и др./ Под общей ред. Р.Н. Минниханова, Д.М. Мустафина. – Казань: ГБУ «НЦ БЖД», 2020 г.

**2 тема: Туган ягым – Татарстан. Яшәгән җиребез.** Туган шәһәребез – Түбән Кама. Аның географик урыны, экологик хәле. Урамнары, чишмәләре. Атрибутика һәм символикасы. Климаты. Шәһәребезнең почетлы кешеләре. Беренче төзүчеләре. Туган көне.

**3 тема: Терек һәм терек булмаган табигать. Табигать күренешләре.** Табигать һәм без. Терек һәм терек булмаган табигать арасындагы бәйләнеш. Үсемлекләр, бөҗәкләр, хайваннар һәм кошлар тормышы. Ел фасылларына хас – сезонлы күренешләр. Метериология фәне. Халык сынамышлары.

**4 тема: Экология һәм Мин. Экологиянең мөһим нигезләре.** Планета тереклеге (Кызыл китап буенча). Саклана торган тыюлыклар, территорияләр. Аларның төрләре. Экологик этика. Агымдагы контроль. Тест № 5 “Табигатькә куркыныч яный!”

*Практика.* Экологик ситуацияләрне чишү.

**5 тема: Безнең урман байлыклары.** Урманда үсүче агачлар, куаклар, дару үләннәре, җиләк-җимешләр. Аларның биологик үзенчәлекләре. Җимешләре, яфраклары, кайрылары, тамырлары, чәчәкләре дару өчен кулланыла торган үсемлекләр. Аларны җыю, киптерү, саклау, дару чималын әзерләү, куллану кагыйдәләре. Кызыл китапка кергән үсемлекләр. Кызыл китапка кергән урман үсемлекләре белән танышу.

*Практика.* Урман үсемлекләре турында табышмаклар, шигырьләр белән танышу, җырлар өйрәнү. Рәсемнәр ясау. Дару үләннәре белән чәй эчү. Гербарий ясау. Балаларның белемнәрен тикшерү. Дару үсемлекләрен куллану буенча рецептлар язу. Юл йөрү кагыйдәләре буенча әңгәмә.

**6 тема: Татарстанда үсүче агулы үсемлекләр.** Агулы үсемлекләр һәм агулы дару үләннәре. Аларның агулы һәм файдалы яклары, биологик үзенчәлекләре. Чәчәкләре, җимешләре, яфраклары, тамырлары дару өчен кулланыла торган агулы үләннәр, аларны җыю, киптерү, саклау, куркынычсызлык кагыйдәләре. Юл йөрү кагыйдәләре буенча әңгәмә.

*Практика.* Кызыл китапка кергән агулы гөмбәләр белән танышу. Аларның рәсемнәрен ясау. Агулы гөмбәләрне аера белергә өйрәнү. Балаларның белемнәрен тикшерү. Агулы дару үсемлекләрен куллану буенча рецептлар төзү. Урман үсемлекләрен җыю, гербарий төзү.

**7 тема: Иҗади эшләр күргәзмәсе**. Балаларның ел буена эшләгән эшләреннән күргәзмә ясау. Балаларның эшләренә нәтиҗә ясау. Тәбрикләү.
**8 тема: Йомгаклау.** Урманда үсүче дару үсемлекләре буенча белемнәрне тикшерү. Арадаш контроль. Викторина № 6 "Гөмбәләр дөньясында".
**9 тема: Укыту модуле "Юл куркынычсызлыгы"**. Саф һавада хәрәкәтле уеннар.

## 3 ЕЛ УКЫТУГА УКУ ПЛАНЫ

| № п/п | Бүлек исеме, темалар | Сәгатьләр саны | | | Аттестация төрләре, тикшерү ысуллары |
|---|---|---|---|---|---|
| | | Барлыгы | Теория | Практика | |
| **1.** | **Кереш өлеш.** Куркынычсызлык кагыйдәләре. Кереш контроль. Тест № 7 "Чәчәкләр дөньясы" | 6 | 3 | 3 | Телдән сораштыру. Күзәтү. Тестлар чишү |
| **2.** | **Туган җирем - Татарстан. Туган шәһәрем –Түбән Кама**. Герб. Флаг. Атрибутика һәм символика. Гаилә паркы. Табигатькә экскурсия | 36 | 18 | 18 | Кечкенә-выставка, презентация эшләре |
| **3.** | **Бүлмә үсемлекләре**. Бүлмә үсемлекләренең биологик үзенчәлекләре. Үстерү, үрчетү ысуллары | 24 | 12 | 12 | Әңгәмә, аралашу, үзлектән эш, практик эш |
| **4.** | **Бакча гөлләре.** Береллык чәчәкләр. Купеллык чәчәкләр. Суганчадан үсүче чәчәкләр. Агымдагы контроль № 8. Проект эшләрен яклау "Минем шәһәрем. Кичә. Бүген. Иртәгә" | 42 | 24 | 18 | Сораштыру. Практик эш. Проект эшләрен яклау |
| **5.** | **Басу һәм болын үсемлекләре.** Биологик үзенчәлекләре. Химик составы. Фәнни һәм халык медицинасында дару чималы булып кулланылучы үсемлекләр. Кызыл китапка кергән үсемлекләр | **36** | **18** | **18** | Кечкенә-выставка, сораштыру |
| **6.** | **Дымлы, сазлы урыннарда, сулыкларда үсүче дару** | **30** | **18** | **12** | "Экология әлифбасы" |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | **үсемлекләре.** Биологик үзенчәлекләре. Химик составы. Чәчәге, яфрагы, тамыры фәнни һәм халык медицинасынды кулланыла торган үсемлекләр | | | | проектын яклау |
| **7.** | **Чүп үләннәре.** Биологик үзенчәлекләре, химик составы. Чәчәге, яфрагы, тамыры фәнни һәм халык медицинасында дару өчен кулланыла торган үләннәр. Аларны җыю, киптерү, саклау ысуллары. Дару чималын әзерләү, куллану кагыйдәләре | **24** | **12** | **12** | Әңгәмә, аралашу, үзлектән эш, практик эш |
| **8.** | **Участокта язгы эшләр.** Мәктәп янында урнашкан участокта язгы эшләр. Орлыкларны сортировка ясау. Орлыклар чәчү | **6** | **3** | **3** | Эшлекле уен, аралашу, сораштыру. Практик эш |
| **9.** | **Йомгаклау.** Йомгаклау аттестациясе. Конкурс үткәрү. Табигатьтә белемнәрен тикшерү. Йомгаклау күргәзмәсендә мөстәкыйль эшләгән эшләрне кую, бәяләү | **12** | **6** | **6** | Практик эш. Йомгаклау аттестациясе |
| | **Барлыгы:** | **216 с.** | **114 с.** | **102 с.** | |

## 3 ЕЛ УКЫТУГА ПРОГРАММА ЭЧТӘЛЕГЕ

**1 тема: Кереш дәрес.** Түгәрәкнең максаты, мәсьәләләре. Куркынычсызлык һәм юл йөрү кагыйдәләрен искә төшерү. Кереш контроль.Тест № 7 “Чәчәкләр дөньясы”.
*Практика.* Көзге табигатькә экскурсия. Юл йөрү кагыйдәләре буенча әңгәмә.
**2 тема: Туган җирем – Татарстан. Туган шәһәрем – Түбән Кама**. Герб. Флаг. Атрибутика һәм символика. Гаилә паркы. Табигатькә экскурсия.
**3 тема: Бүлмә үсемлекләре.** Бүлмә гөлләрен үрчетү ысуллары. Аларның авырулары. Бүлмә гөлләрен утырту һәм карау. Аларның биологик үзенчәлекләре һәм үстерү кагыйдәләре. Дару чималы буларак кулланучы өлешләре. Химик составы. Дару чималын әзерләү һәм куллану кагыйдәләре.
*Практика.* Бүлмә гөлләрен тәрбияләү. Алар турында шигырьләр, легендалар, җырлар белән танышу. Рәсемнәрен ясау. Рецептлар төзү. Белемнәрен тикшерү. Даруханәгә экскурсия.
*Кулланма материал:* бүлмә гөлләре, җир, савытлар.

**4 тема: Бакча гөлләре.** Берьеллык һәм күпеллык чәчәкләр. Суганчалы чәчәкләр. Чәчәкләр аранжировкасы.
*Практика.* Бакча гөлләренең орлыкларын җыю һәм киптерү.
Агымдагы контроль. Проект эшләрен яклау "Минем шәһәрем. Кичә. Бүген. Иртәгә".
*Кулланма материал:* орлыклар, кипкән һәм тере чәчәкләр, кәгазь, җилем, буяулар.
**5 тема: Басу һәм болын үсемлекләре.** Басу һәм болын үсемлекләре, аларның биологик үзенчәлекләре, химик составы. Фәнни һәм халык медицинасында дару чималы булып кулланылучы үсемлекләр. Кызыл китапка кергән үсемлекләр.
*Практика.* Җыю, киптерү, саклау кагыйдәләре. Үсемлекләрдән гербарий төзү. Болын һәм басу үсемлекләре турында табышмаклар, шигырьләр, җырлар белән танышу. Дару үсемлекләре белән чәй эчү. Дару үләннәрен куллану буенча рецептлар төзү. Белемнәр тикшерү. Көзге табигатькә экскурсияләр.
*Кулланма материал:* орлыклар, кипкән һәм тере чәчәкләр, кәгазь, җилем, буяулар.
**6 тема: Дымлы, сазлы урыннарда, сулыкларда үсүче дару үсемлекләре.** Дымлы, сазлы урыннарда, сулыкларда үсүче дару үсемлекләре. Аларның биологик үзенчәлекләре, химик составы. Чәчәге, яфрагы, тамыры фәнни һәм халык медицинасынды кулланыла торган үсемлекләр. Кызыл китапка кергән үсемлекләр.
*Практика.* Дару үләннәренең рәсемнәрен ясау. Реептлар төзү. Алар турында шигырләр эзләү. Кызыл китап белән эшләү. Белемнәрен тикшерү. Юл йөрү кагыйдәләре буенча әңгәмә.
*Кулланма материал:* орлыклар, кипкән һәм тере чәчәкләр, кәгазь, җилем, буяулар.
**7 тема: Чүп үләннәре.** Чүп үләннәре. Аларның биологик үзенчәлекләре, химик составы. Чәчәге, яфрагы, тамыры фәнни һәм халык медицинасында дару өчен кулланыла торган үләннәр. Аларны җыю, киптерү, саклау ысуллары. Дару чималын әзерләү, куллану кагыйдәләре.
*Практика.* Чүп үләннәре турында табышмаклар, шигырьләр, җырлар белән танышу. Аларның рәсемнәрен ясау. Үләннәр җыю. Гербарий төзү. Дару үләннәре белән чәй эчү. Яшь үләннәрдән салатлар ясау. Рецептлар төзү. Белемнәрен тикшерү. Язгы табигатькә экскурсияләр.
**8 тема: Участокта язгы эшләр.** Мәктәп янында урнашкан участокта язгы эшләр. Орлыкларны сортларга аеру. Орлыклар чәчү.
**9 тема: Йомгаклау.** Конкурс үткәрү. Табигатьтә белемнәрен тикшерү. Йомгаклау күргәзмәсендә мөстәкыйль эшләгән эшләрне кую, бәяләү. Йомгаклау аттестациясе.

## ПРОГРАММАНЫҢ ПЕДАГОГИК-ОЕШТЫРУ ШАРТЛАРЫН ТОРМЫШКА АШЫРУ

**Материаль-техник база:**
1. *Җылы, якты сыйныф бүлмәсе.*
2. *Җиһазлар:*
- укучылар өстәле - 15 шт.;
- укучылар урындыгы – 30 шт.;
- укытучы урындыгы – 1 шт.;
- укытучы өстәле -1 шт.;
- стена тактасы – 1 шт.;
- шкаф – 1 шт.

3. *ТСО чаралары*
- ноутбук -1 шт
- колонкалар - 2 шт
- мультимедиа проектор, экран

4. *Материаллар һәм җиһазлар*:
- клей, төсле кәгазь, картон, схемалар, шаблоннар, акварель буяулар, таблицалар, кроссвордлар, төсле каләмнәр, кайчылар, фигуралы дыраколлар, пластилин, дренаж, җир, гөл савытлары, кечкенә көрәкләр, лейкалар, орлыклар.

Дидактик материаллар (демонстратив һәм тарату) - журналлар, буклетлар, альбомнар, карточкалар,схемалар. , кайчылар, фигуралы дыраколлар, пластилин, дренаж, җир, гөл савытлары, кечкенә көрәкләр, лейкалар, орлыклар.

*“Туган як табигатен өйрәнү" берләшмәсендә дәресне оештыру түбәндәге таләпләргә җавап бирә:*

● төбәк туристлык берләшмәсе белән танышу, сөйләм культурасын үстерү, табигать матурлыгына соклану уяту;
● уку материалы дәреснең максаты һәм эчтәлеге нигезендә сайлап алына;
● дәрес формалары: коллектив, инвивидуаль, төркем белән;
● дәреснең темасы һәм эчтәлеге буенча укыту методларының һәм алымнарының туры килүе.

*Методлар һәм алымнар.*

Әлеге программаны уңышлы тормышка ашыру өчен укучыларда тотрыклы кызыксыну булдырырга ярдәм итә торган заманча ысуллар кулланыла.

*Эшчәнлекнең төрләре.*

● яңа белем алу (укытучы теоретик мәгълүматны хәбәр итә). Мондый төрдәге дәрестә укучы яңа тема белән таныша;
● белем һәм күнекмәләрне формалаштыру дәресләре (педагог җитәкчелегендә мөстәкыйль эшчәнлек);
● кабатлау (материалны үзләштерүнең сыйфатын билгели), мондый дәресләр йомгаклау дәресе булып торалар;
● катнаш дәрес (берничә укыту бурычын чишү). Теманың үзенчәлегенә карап индивидуаль, төркемләп шөгыльләнергә мөмкин.

*Эмоциональ:* уңыш ситуациясе, бүләкләү һәм шелтәләү, танып-белү, билгеле шәхес булу теләген үстерү.

*Ихтыяри:* укучыларның белем алуга карата җаваплы карашын формалаштыру. *Социаль:* үзара ярдәмләшү ситуацияләре булдыру, коллектив эш нәтиҗәләре белән кызыксындыру.

*Танып-белү*: укучының субъектив тәҗрибәсенә таяныч, иҗади мөмкинлекләрен хәл итү, проблемалы ситуацияләрне булдыру.

Дәрес берничә этаптан тора:

● Күрсәтмә-методик рәтне аңлату һәм үсемлекләр дөньясы буенча репродукцияләр демонстрацияләү, күрсәтмә материаллар белән эшләү, табигатьтә шул үсемлекне табу, аның үзенчәлекләрен күрсәтә белү, чагыштыру, укучыларның кабул итүе аша педагог фикер алышулар оештыру;
● Схемалар ярдәмендә биремнәрне үтәү;

● Йомгак ясау, башкарган биремнәргә анализ ясау, күргәзмә оештыру.

Эш алымнары һәм методлары:

● Төрле бәйгеләрдә, күргәзмәләрдә актив катнашу;
● Шәһәребезнең куренекле шәхесләре белән очрашулар оештыру;
● Шәһәребезнең музейларына экскурсияләр оештыру;
● Балалар коллективын булдыру һәм үстерү.

**Аттестация формалары/контроль һәм бәяләү материаллары**

Укучыларның программа материалын үзләштерү киләсе контрольне үткәрү барышында күзәтелә:

- *Кереш контроль*. Ул һәр уку елы башында, белем бирү процессы башланганчы укучының белем дәрәҗәсен бәяләү өчен үткәрелә. Ул төп терминология һәм декоратив-гамәли иҗат өлкәсендә эш ысуллары һәм алымнары буенча сораштыру, әңгәмә рәвешендә уза.
- *Агымдагы контроль.* Программаны гамәлгә ашыруның бөтен срогы дәвамында (зур бүлекне өйрәнү тәмамланганнан соң, ярты еллыкта) үткәрелә. Мөстәкыйль практик эш, сораштыру, тестлар, конкурсларда, күргәзмәләрдә үз эшләре белән катнашу, иҗади проектны яклау рәвешендә узарга мөмкин.
- *Арадаш аттестация.* Программаны үзләштерү нәтиҗәлелеген билгеләү өчен үткәрелә. Укытуның беренче, икенче ел ахырында викторина, тест формаларында уздырыла.
- *Йомгаклау контроле.* Программаны өч ел уңышлы үзләштергәннән соң уздырыла. Укуның өченче ел ахырында (программа буенча тулы курсны тәмамлаганнан соң) Балалар һәм яшьләр иҗаты сараенда уздырылган йомгаклау күргәзмәсендә иҗади эшләрен яклау рәвешендә уздырыла.

| ***Үткәрү вакыты*** | ***Үткәрү максаты*** | ***Аттестация һәм контроль формалары*** |
|---|---|---|
| **1 ел укыту<br>Кереш контроль** | | |
| 1 ел укыту башында (сентябрь) | Балаларның башлангыч белем дәрәҗәләрен һәм аларның иҗади сәләтләрен билгеләү | Әңгәмә, телдән сораштыру, кечкенә тестлар чишү. Анкета уздыру |
| **Агымдагы контроль** | | |
| 1 ел укыту уртасында (декабрь) | Укучылар тарафыннан уку материалының үзләштерү дәрәҗәсен билгеләү. Укучыларда укуга карата җаваплылык һәм кызыксыну уяту. Укуда алга киткән һәм үзләштермәгәннәрне барлау. Укытуда аеруча нәтиҗәле чараларны сайлап алу. Әйләнә - тирә объектларны күзәтү, алган күзәтү | Педагогик күзәтү, контроль дәрес, мөстәкыйль эш, тестлар үткәрү “Туган ягым - Татарстан!” |

| | | |
|---|---|---|
| | нәтиҗәләрен чагыштырып, аңлата белү | |
| **Арадаш контроль** | | |
| 1 ел укыту ахырында (май) | Балаларның уку матералын үзләштерүен тикшерү. Алган белемнәрен һәм күнекмәләрен тормышта куллана белүләрен күзәтү | Тестлар уздыру “Безнең як үсемлекләре” |
| **2 ел укыту<br>Кереш контроль** | | |
| 2 ел укыту башында (сентябрь) | Укучыларның туган як темасы буенча әзерлек сыйфатын бәяләү | Тестлар уздыру ”Татарстан минем республикам” |
| **Агымдагы контроль** | | |
| 2 ел укыту (декабрь) | Укучылар тарафыннан уку материалының үзләштерү дәрәҗәсен билгеләү. Әйләнә - тирә объектларны күзәтү, алган күзәтү нәтиҗәләрен чагыштырып, аңлата белү | Тестлар уздыру “Табигатькә куркыныч яный!” |
| **Арадаш контроль** | | |
| 2 ел укыту (май) | Балаларны табигать белән тыгыз элемтәдә булуларын тикшерү. Тирә - як мөхиткә сакчыл караш тәрбияләү | Викторина “Гөмбәләр дөньясында” |
| **3 ел укыту<br>Кереш контроль** | | |
| 3 ел укыту башында (сентябрь) | Бакчаларда үсүче чәчәкләр турында булган белемнәрен тикшерү, белем дәрәҗәләрен тормыш белән бәйләү | Тестлар уздыру “Чәчәкләр дөньясы” |
| **Агымдагы контроль** | | |
| 3 ел укыту (декабрь) | Туган шәһәребез турында алган белем дәрәҗәләрен тикшерү. Патроитик хисләр тәрбияләү. Алган белемнәрен иҗади эшләрендә куллана белү | Проект эшләрен яклау “Минем шәһәрем. Кичә. Бүген. Иртәгә” |
| **Йомгаклау контроле** | | |
| 3 ел укыту ахырында (май) | Балаларның уку матералын үзләштерүен тикшерү. Алган белемнәрен һәм | Балалар һәм яшьләр иҗаты сараенда оештырылган йомгаклау күргәзмәсендә |

| | | |
|---|---|---|
| | күнекмәләрен тормышта куллана белүләрен күзәтү | иҗади эшләре белән катнашу |

*Педагогик мониторинг.*

Программаны уңышлы үзләштерү өчен эшчәнлек нәтиҗәләрен өзлексез һәм системалы тикшерү сорала.

| **Параметрлар** | **Бәяләмә** |
|---|---|
| Белем бирү нәтиҗәсе | Балалар тарафыннан укыту эшчәнлеген үзләштерү. Күнекмәләр төрлелеге.<br>Предмет буенча белем тирәнлеге. Укучыларның практик һәм иҗади казанышлары. Укытуда тотрыклы кызыксындыру эшчәнлегенең актив позициясе. |
| Тәрбия бирү нәтиҗәсе | Үз-үзеңне тоту культурасы.<br>Бирелгән биремнәрне дөрес итеп үтәү, эш урынын тәртиптә тоту. Башлаган эшне ахырына җиткерү. |
| Социаль-педагогик нәтиҗә | Санитария-гигиена таләпләрен үтәү. Куркынычсызлык техникасы таләпләрен үтәү. Коллективта мөнәсәбәт. Педагогка карата мөнәсәбәт. |

Күрсәткечләр – югары, уртача, түбән булулары белән бәяләнәләр.

Укыту нәтиҗәлеге мониторингы программаның һәр бүлеге беткәннән соң үткәрелә.

- Предмет буенча белем тирәнлеге.

*Югары*: программа буенча киң белемгә ия, туган як табигате буенча кирәкле терминнарны иркен куллана, өстәмә әдәбияттан файдалана.

*Уртача:* программа буенча тулы булмаган белемгә ия, туган як табигате буенча аерым терминнарны белә, өстәмә әдәбияттан файдаланмый.

*Түбән:* программа буенча белеме җитәрлек түгел, аерым билгеләмәләрне генә белә.

- Эшчәнлеккә тотрыклы кызыксыну һәм укытуда актив позиция булдыру.

*Югары*: эшчәнлеккә актив кызыксындыру булдыру, өйдә мөстәкыйль шөгыльләнү, башкаларга ярдәм күрсәтү, бәйгеләрдә актив катнашу.

*Уртача:* эшчәнлеккә кызыксыну күрсәтә, максатка ирешүдә эшнең бер этабында активлык күрсәтә.

*Түбән:* актив түгел, педагог кушуы буенча билгеле бер эшне генә башкара.

- Иҗат уңышлары төрлелеге.

*Югары:* теләсә нинди масштабтагы бәйгеләрдә, чыгышларда даими катнаша.

*Уртача*: учреждение, берләшмә эчендәге бәйге, чыгышларда катнаша.

*Түбән:* берләшмә эчендәге чараларда сирәк катнаша.

- Гомуми танып-белү сәләтләрен үстерү.

*Югары:* туган ягыбыз табигатендә үсүче үсемлекләрне яхшы таный, тирән фикер йөртә, иҗади күзаллау яхшы формалашкан, игътибары тотрыклы.

*Уртача:* туган ягыбыз табигате турында иҗади күзаллау яхшы формалашкан, үсемлекләрне дөрес аеру өчен педагог ярдәме кирәк, сорауларга җавапларны озак уйлаганнан соң гына бирә.

*Түбән:* туган як табигате турында фикер йөртүе түбән, иҗади кузаллау начар формалашкан, үсемләрнең исемнәрен белми , сорауларга җавап бирми.

*Тәрбия чараларының нәтиҗәлеген мониторинглау:*

- Баланың үз-үзен тотышы.

*Югары:* әдәплелек кагыйдәләрен саклый, әхлакый фикерләү сыйфатларына ия (игелеклелек, хөрмәт итү, дисциплина).

*Уртача:* әдәплелек кагыйдәләрен белә, аларны үти.

*Түбән:* әдәплелек кагыйдәләре норма белән туры килми. Үз-үзеңне дөрес тоту кагыйдәләрен сирәк үти.

- Коллективка карата мөнәсәбәт.

*Югары:* югары коммуникатив сыйфатларга ия, коллектив эшләрендә актив катнаша.

*Уртача:* коммуникатив сыйфатларга ия, тик коллектив эшләрендә катнашырга ояла.

*Түбән:* коммуникатив сыйфатлар түбән, коллектив белән аралашу теләге юк.

*Социаль-педагогик нәтиҗәләр мониторингы:*

- Санитар-гигиена таләпләрен үтәү.

*Югары :*пөхтә һәм чиста йөри, иҗади эшләр өчен папкасы тәртиптә.

*Уртача:* педагог санитар-гигиена таләпләрен искә төшергәннән соң гына үти.

*Түбән:* санитар-гигиена таләпләрен үтәү белән бик сирәк ризалаша.

- Куркынычсызлык техникасы таләпләрен үтәү.

*Югары:* практик эшләр вакытында барлык куркынычсызлык техникасы кагыйдәләрен башкара.

*Уртача:* куркынычсызлык техникасы кагыйдәләрен педагог искә төшергәндә үти.

*Түбән:* куркынычсызлык техникасы кагыйдәләрен укытучы контрольдә тотканда гына үти.

- Коллективка карата мөнәсәбәте.

*Югары*: игелекле, коллективта һәркемгә ярдәм итәргә омтыла, күмәк эшләрдә катнашырга теләк белдерә.

*Уртача:* низахлашмый, иптәшләре белән хезмәттәшлек итәргә омтылмый.

*Түбән:* иптәшләре белән хезмәттәшлек итүдән баш тарта.

- Педагогка мөнәсәбәт.

*Югары:* игътибарлы һәм илтифатлы, сораулары булса ярдәм сорап мөрәҗәгать итә.

*Уртача:* педагог таләпләрен башкара.

*Түбән:* таләп иткәннән соң гына сорауларга җавап бирә.

Белем бирү программасында билгеләнгән тәрбия бурычларының тормышка ашырылуы аша “Туган як табигатен өйрәнү” берләшмәсенә йөрүче укучылар муниципаль, республика, бөтенроссия, халыкара чараларда, бәйгеләрдә, кичәләрдә һ.б катнашалар.

*Нәтиҗәләр чыгаруның төп формалары:*

3 елга исәпләнгән “Туган як табигатен өйрәнү” программасын тормышка ашыруны ачык дәресләр, әти-әниләр белән төрле бәйрәм кичәләре оештыру, күп төрле экологик акцияләрдә, конкурсларда, фестивальләрдә актив катнашу шәһәр күләмендә уздырылучы бәйрәм-кичәләрендә чыгыш ясаулар тәшкил итә.

Өстәмә белем программасын, йомгаклау аттестациясен уңышлы узган балага таныклык бирелә.

БЕЛЕМ ДӘРӘҖӘСЕН ТИКШЕРҮ МАТЕРИАЛЛАРЫ

**1нче ел укыту**

**Кереш контроль**

**Максат:** балаларның туган як табигатебез турында булган башлангыч белемнәрен тикшерү**.**

**Контроль формасы:** телдән әңгәмә, сораштыру. Тестларга дөрес җаваплар табу.

**Тест**

1. **"Табигать" төшенчәсенә туры килүче сүзләрне язып алырга:**

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| Кар | болыт | коңгыз | бүре | боз | кирпеч |
| чүкеч | ком | кәрәс | имән | ромашка | су |

Терек булмаган табигатьне белдерүче сүзләрнең астына сары карандаш белән сызарга, терек табигатьне белдерүче сүзләрнең астына яшел карандаш белән сызарга.

2. **Һава температурасын үлчәүче приборның исемен язып ал:**

| | | |
|---|---|---|
| Үлчәү | спидометр | термометр |
| Монометр | сәгать | метр |

3. **Җөмләләрне тулыландыр:**

Су җылынганда _________________ әйләнә.

Су суынганда ____________________ әйләнә.

4**. Күчмә кошларның исемнәрен язып ал:**

Песнәк, торна, карлыгач, күгәрчен, кыр үрдәге, сыерчык, челән, саескан, кыр казы, сандугач.

5**. Кешенең табигатькә дөрес мөнәсәбәтен күрсәткән юлларны тап:**

а) Урманнарны кисеп бетерү;

б) Агач һәм куаклар утырту;

в) Калдык - постыкларны суга ташлау;

г) Зоопарклар булдыру.

6. **Нәрсә ул глобус?**

а) Җир шары;

б) Җир өслеге;

в) Рәсемле шар.

7. **Ылыслы үсемлекләр яфраклы үсемлекләрдән нәрсә белән аерыла?**

а) Ылыслы үсемлекләр яфраклы үсемлекләрдән тәбәнәк;

б) Ылыслы үсемлекләрнең яфраклары- ылыслар;

в) Ылыслы үсемлекләр урманда гына үсә.

8. **Агулы гөмбәләрне тап:**

а) Ак гөмбә;

б) Үтле гөмбә;
в) Чебен гөмбәсе;
г) Усак гөмбәсе.

9. **Җөмләләрне тулыландыр:**
Кеше тарафыннан үстерелгән үсемлекләр ________________ дип атала.
Кыргый табигать шартларында үскән үсемлекләр ____________ дип атала.

10. **Нинди хайваннарны йорт хайваннары дип атыйлар?**
а) Кеше янында яши торган барлык хайваннарны;
б) Кеше тарафыннан үрчетелә, тәрбияләнә, файдаланыла торган хайваннарны;
в) Үрчергә сәләтле барлык хайваннарны.

**Дөрес җаваплар:**

1. 1; 3; 5; 8; 9;10;12
2. 6
3. Пар, боз
4. 2, 3 ,5, 6, 7,9,10
5. б), г)
6. б)
7. б)
8. в)
9. Культуралы, кыргый
10. б)

**Бәяләү критерийлары:**

| Дәрәҗә | Балл |
|---|---|
| Югары | 10 |
| Уртача | 9 - 5 |
| Түбән | 4 эзерәк |

**Агымдагы контроль**

**Максат:** туган шәһәребез, республикабыз турында алган белемнәрен тикшерү.
**Контроль формасы:** “Туган ягым –Татарстан” тестына дөрес җаваплар язу.

**Тест**

**1. Россия Федерациясе субъектларының кайсысында Түбән Кама урнашкан?**
1) Татарстан; *
2) Башкортостан;
3) Адыгея.

**2. Түбән Камага кайсы елда шәһәр статусы бирелде?**
1) 30 август 1990 ел;
2) 12 июнь 1958 ел;
3) 22 сентябрь1966 ел. *

**3. Завод комплексының кайсы тибында Түбән Кама торгызылды?**
1) Химия заводлары янында; *

2) Автомобиль заводлары янында;
3) Суднолар төзү заводлары янында.

**4. Түбән Кама нинди елга ярында тора?**
1) Нократ;
2) Идел;
3) Кама. *

**5. Түбән Кама кайсы елда беренче тапкыр «Россиянең иң төзек шәһәре» исеменә лаек булды?**
